ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Дубъязы, ул. Ленина, 28

тел./факс 8(84365) 61-2-86, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**18 июль 2022 ел** **№ 51**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 150 номерлы карары белән кабул ителгән (Советның 07.08.2020 № 168, 15.01.2021 N17 карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында, әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбьяз авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 октябрендагы 40 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2021 елның 04 октябрендагы 40 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 25 октябренда 10.00 сәгатьтә Биектау районы, Дөбьяз авылы, Ленин урамы, 28 нче йорт адрес буенча үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 150 номерлы карары белән кабул ителгән (Советның 07.08.2020 № 168, 15.01.2021 N17 карарлары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Галиуллин Р.Ш.